ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ГОРОДА
ИННОПОЛИС

ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис,
Верхнеуслонский район,
Республика Татарстан, 420500

ИННОПОЛИС
ШӘҺӘРЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис
шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан
Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                                                    КАРАР

г. Иннополис                                                                    №

05.04.2021                                                                    №62

«Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү комиссиясе турында» Иннополис шәһәре Башкарма комитетының 2015нче елның 27нче августындагы 20нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Штаттагы вазыйфаи үзгәрешләр һәм муниципаль хезмәт вакантлы вазыйфасын биләп торуга конкурс үткәрү буенча комиссия эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007нче елның 2нче мартындагы 25-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Муниципаль хезмәт турында 2013нче елның 25нче июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы нигезендә , Иннополис шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Иннополис шәһәре Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү комиссиясе турында» 2015 елның 27 августындагы 20 номерлы карарына (Иннополис шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 26 гыйнварындагы 01 номерлы; 25.11.2016 ел, № 34; 20.03.2017 ел, №07; 06.04.2017 ел, № 11; 04.09.2017 ел, № 35; 28.03.2018 ел, №17; 04.10.2018 ел, № 60; 22.10.2020 ел, № 47 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү буенча Комиссия составына кертергә:

- Хөҗҗәтов Илдар Равил улы, Иннополис шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары.

1.2. Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү комиссиясе составыннан төшереп калдырырга:

- Афанасьева Вероника Валерьевна, хокукый ярдәм бүлеге начальнигы.

2. Иннополис шәһәре Башкарма комитетының 2020нче елның 22нче октябреннән 47нче номерлы Карарына Кушымта үз көчен югалткан дип танырга.

3. Комиссия составын әлеге Карарга Кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Интернет - телекоммуникация челтәрендә (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru), Иннополис шәһәре мэриясе бинасында урнашкан махсус мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга .

5. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Җитәкче Р. Р. Шагалиев

Иннополис шәһәре Башкарма комитетының
2021нче елның 5нче апреленнән
62нче номерлы Карары белән
Расланган

Иннополис шәһәре Башкарма комитеты муниципаль хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү буенча комиссия составы

| | |
|---|---|
| | Комиссия рәисе: |
| Шагалиев Руслан Ринат улы | Җитәкче |
| | Комиссия секретаре: |
| Денисова Наталья Александровна | Иннополис шәһәре Башкарма комитеты кадрлар эше буенча баш белгеч |
| | Комиссия әгъзалары: |
| Хөҗҗәтов Илдар Равил улы | Иннополис шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары |
| Ушакова Жанна Владимировна | Иннополис шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең урынбасары |
| Астраханцева Светлана Витальевна | Иннополис шәһәре Башкарма комитетының финанс бүлегенең икътисад һәм планлаштыру буенча баш белгеч |